**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы**
**Яңаиглай авыл җирлеге советы**

# КАРАР

19 декабрь2018 ел № 93

**Яңаиглай авыл җирлеге Советының 2017елның 24 мартындагы№ 46 «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Янаиглай авыл җирлеге Советының муниципаль хезмәтләр Нигезләмәсе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәтләр турында»гы 2007 елның 2 мартындагы №25-ФЗ Федераль Законга, «Коррупциягә каршы тору турында, Россия Федерациясенең 208 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ Федераль Законга, 2018 елның 17 июлендәге Татарстан РеспубликасыЗаконының№50-ТРЗ «Татарстан Республикасында гражданлык хезмәтләре турында» гы Законының 10 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» һәм муниципаль хезмәтләр турында Татарстан Республикасы Кодексына нигезләнеп

Янаиглай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Янаиглай авыл җирлеге Советының 2017 елның 24 мартындагы «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Янаиглай авыл җирлеге Советының муниципаль хезмәтләр Нигезләмәсе турында»гы № 46 карарына (Янаиглай авыл җирлеге Советының 2017елның 27 октябрендәге № 54)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 2 нче бүлегендәге 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Муниципаль хезмәтләр вазыйфасын башкару өчен квалификацион таләпләрнең һөнәри белемгә туры килүе, муниципаль стаж һәм белгечлек буенча эшләү, хезмәт вазыйфаларын башкару өчен тиешле белем һәм күнекмәләр булу, шулай ук, әгәр дә булган очракта, эш бирүченең карары.

Муниципаль хезмәтләр вазыйфасын башкару өчен квалификацион таләпләр Татарстан Республикасының муниципаль хезмәтләр Кодексында билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфаларына караган типовой квалификацион таләпләр нигезендәге хокукый актларга таянып билгеләнә. Хезмәт вазыйфаларын башкару өчен белем һәм күнекмәләргә тиешле таләпләр муниципаль хезмәтнең кайсы өлкәсендә эшләвенә карап вазыйфаи инструкция белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясендә белгечкә квалификацион таләпләр дә күрсәтелергә мөмкин.

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкару өчен түбәндәге типовой квалификацион таләпләр куела:

1) һөнәри яктан: югары, баш һәм әйдәп баручы вазыйфалар өчен югары белем; өлкән һәм кече төркемдәге вазыйфалар өчен – югары яки урта һөнәри белем;

2) муниципальхезмәтстажына яки белгечлек буенча эш стажына:

Югары вазыйфадагы муниципаль хезмә төчен – ике елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажыя исә дүрт елдан ким булмаган белгечлек буенча стаж;

Баш вазыйфадагы муниципаль хезмәт өчен – бер елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яисә ике елдан ким булмаган белгечлек буенча стаж.

Әйдәп баручы, өлкән һәм кече төркемдәге муниципаль хезмәт вазыйфалары өчен муниципаль хезмәтстажы, белгечлек буенча стаж таләп ителми.

Муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә дәүләт гражданлык хезмәтләрендә, аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәтләрдә һәм федераль дәүләт хезмәтләренең башка төрләрендә эшләүләре исәпкә алына.

Үз белгечлеге буенча муниципаль хезмәткәрләргә куелган квалификацион таләпләргә туры килә торган эшкә урнашса, муниципаль хезмәт вазыйфалары

Буенча ярты ел, белгечлек буенча бер ел эш стажы таләп ителә»;

14бүлекнең1.2пунктынтүбәндәгередакциядәбирергә:

«8. Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәр, муниципаль хокукый актларның проектларын эшкәрткән өчен, вазифаи инструкцияләрдә курсәтелгән бурычларны чишүне башкарган өчен муниципаль хезмәткәрләргә премияләр эш бирүче карарын буенча түләнә.

Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәр, муниципаль хокукый актларның проектларын эшкәрткән өчен, вазифаи инструкцияләрдә курсәтелгән бурычларны чишүне башкарган өчен муниципаль хезмәткәрләргә премияләр абсолют күләмдә билгеләнә, шулай ук муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның хезмәте өчен түләү айлык акчалата бүләк һәм айлык акчалата бүләк рәвешендә башкарыла.

Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәр, муниципаль хокукый актларның проектларын эшкәрткән өчен, вазифаи инструкцияләрдә курсәтелгән бурычларны чишүне башкарган өчен муниципаль хезмәткәрләргә премияләр хезмәткә түләү форндында каралган средстволар кысаларында түләнә.

1.3 Нигезләмәнең14 нче бүлегендәге 13 пунктындагы 6нчы абзацны түбәндәге редакциядәбирергә:

“Өстәмә матди ярдәм эш бирүче тарафыннан түбәндәге очракларда өстәмә түләнергә мөмкин: бала туганда, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең яки аның туганнарының тормышында бәхетсезлек очраклары килеп чыкканда. “

2. Әлеге карарны Янаиглай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңаигай авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге советы рәисе Ф.С. Гайнуллин